Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге составына керүче
Татар Тәкәше авылында
Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«25»ноябрь 2022 ел №9

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 20 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2023 елның 25 ноябрендә 15.00 сәг.Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылында гражданнар җыенында «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?" дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде

1.Татар Тәкәше авылына юлларны кардан чистарту
2. Татар Тәкәше авылында суүткәргеч торбалар, тоташтыру муфталары сатып алу
3. Татар Тәкәше авылында суүткәргеч торбаларны алыштыру буенча хезмәтләргә түләү.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 49 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 49 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" - 49 граждан тавыш бирде;

"ЮК" - 0 граждан.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?" дигән сорауга карарны танырга.

1.Татар Тәкәше авылына юлларны кардан чистарту

2. Татар Тәкәше авылында сууткәргеч торбалар, тоташтыру муфталары сатып алу

3. Татар Тәкәше авылында сууткәргеч торбаларны алыштыру буенча хезмәтләргә түләү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов